**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы**

**КАРАР 89**

**Югары Сәрдә авылы** **24 октябр 2024 ел**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендә кабул ителгән 105 номерлы «Җир салымы турында" карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендә кабул ителгән 105 номерлы «җир салымы турында» ( 20.01.2020 ел г. № 120, 30.10.2020 ел № 7, 30.01.2024 № 78 үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктындагы 2.2 пунктчасында «(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен «, эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән һәм һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2 пунктның 2.3 пунктчасында «, әлеге пунктчада күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган җир кишәрлекләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (www.atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 01.01.2025 елдан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Татарстан Республика
Әтнә муниципаль районы
Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хөснетдинов